**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«23» 05 2023 ел Яр Чаллы № 1576

Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә

## КАРАР БИРӘ:

1. «Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет төзү турында» Тукай муниципаль районы Башарма комитетының 2021 елның 9 сентябрендәге 2634 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Чыгарырга:
- Р.А. Нәҗиповaны;
- А.С. Ибраһимовны;
- И.И. Сәхбетдиновны;
- Г.Г. Сабирҗановны.

1.2. Кертергә:
- М.М. Сафиуллинаны – Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ директоры;
- Ә.З. Сабировны – Тукай муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
- Ю.М. Рыбаковаsuccessfully – Тукай муниципаль районы мәдәният бүлеге башлыгы;
- М.А. Потеевны – «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы.

2. Кертелгән үзгәрешләр белән комиссия составын кушымта нигезендә расларга.
3. Карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында https://tukay.tatarstan.ru/ һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 23.05 1576 номерлы карарына кушымта

**Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет составы**

| | |
|---|---|
| Бариев И.Ш. | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, эшче төркем рәисе; |
| Гәрәев И.Р. | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Сәфиуллина М.М. | - Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ директоры, комиссия секретаре. |

**Эшче төркем әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Сабиров Ә.З. | - Тукай муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Рыбакова Ю.М. | - Тукай муниципаль районы мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Бариева Л.Ф. | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Потеев М.А. | - «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча). |